Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегенең Красновидово авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

2025 елның 5 декабре № 5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авылы:

1.2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегенең Красновидово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча обилизацияләнгән I төркем инвалидлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

» КАРШЫ «ӨЧЕН

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово ав., Совет ур., 4 й.;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас ав., Үзәк ур., 3 й.;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 29а йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге башлыгы: А.А.Болтаков